# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге Мортыштамак авылында
2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2025 елның 13 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегендә гражданнар җыены

Карар:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Мортыштамак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 нче төркем инвалидларыннан, 90 яшькә җиткән ялгыз карт гражданнардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 сум күләмендә үзсалым кертергә .

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Муртыш-Тамак авылында урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы (лампалар, энергияне сак тоту яктырткычлары, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү),

2) Муртыш-Тамак авылының Совет һәм Комсомол урамнары буенча гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау (вак таш-комлы катнашма сатып алу, чокырларга ремонт, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), юлларны кардан чистарту (махсус техниканы карап тоту - ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, МТЗ-82 тракторы өчен запас частьләр сатып алу);

3) Муртыш-Тамак авылындагы Минзәлә елгасы аша җәяүлеләр күпернең конструкциясен буяу (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

4) халыкның күпләп ял итү урынын (триммер һәм газонокосилка сатып алу), (Д.Әхмәтов исемендәге парк, яр буе) ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү ,Совет 47 урамындагы Мәдәният йорты территориясендә югары буйлы агачларны кисү (бензин ягулыгы сатып алу, триммер өчен запас частьләр сатып алу, үләннәр чабып алу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

5) Совет һәм Комсомол урамы зиаратларында ремонт, койма тоту (биек агачларны кисү, өрәңге үсентеләрен юкка чыгару өчен гербицид сатып алу, койма өчен буяу сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

6) Мортыштамак авыл җирлеген 2026 ел өчен үзара салым акчаларыннан янгынга каршы су чыганаклары белән тәэмин итү.

3. Әлеге карарны Мортыштамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль район
Мортыштамак авыл җирлеге
башлыгы: Хафизов И.И.